Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыКүгәрчен авыл җирлеге Советы

**КАРАР № IX**

Күгәрчен авылы 04 сентябрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләре турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә чисталыкны саклау, тәртип һәм төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру максатларында, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 13.04.2017
№711/пр боерыгы белән «җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик рекомендацияләрне раслау турында», Балык Бистәсе муниципаль районы «Күгәрчен авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрченавыл җирлеге территориясен 14.04.2017 елдагы төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен карап, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрченавыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен расларга.

2. 1. Үз көчен югалткан дип танырга:
атарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Советының 01.06.2012 № 5 карары " Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә территорияләрне санитар карап тоту, җыештыру һәм чисталыкны тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында.»;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Күгәрчен авылы,Совет урамы,62а йорт; Зәңгәр-Күл авылы, Тукай урамы , 3а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы БалыкБистәсе муниципаль районының http://ribnaya- sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы А.Т.Сафин